СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

18 июль, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 78 (8090) | Бәясе билгеләнгәнчә

## ИГЪТИБАР: АЛДЫНГЫЛАР СЛЕТЫ

**19 июль көнне Киекле КХАсы базасында район савучыларының слеты була. Анда районда сөт терлекчелегенең узган елның октябрь аеннан быелның июнь аена кадәрге эшчәнлегенә йомгак ясалачак, алдынгылар билгеләнәчәк, тәҗрибә уртаклашу, киңәш-табыш итү мөмкинлеге булачак. Алдынгылар слеты сәгать 10да башлана.**

## ТЕРСӘКНЕ ТЕШЛӘРЛЕК БУЛМАСЫН

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Терлек азыгы хәзерләү кебек мөһим эшнең кичектергесезлеген яхшы аңлаган хуҗалыкларда сенаж базлары тирәсендә җанлылык хөкем сөрә. «Агрохимсервис»ның һәм «Нурлатнефтепродукт»ның ярдәмче хуҗалыкларында бу төр сусыл азык запасы планга карата чагыштырмача ярыйсы гына инде. Аларның беренчесендә соңгы берничә көндә техниканы югары җитештерүчән файдаланып шактый ук массаны базга тутырырга өлгерделәр. «Рассвет», Кузнецов исемендәге, Мичурин исемендәге хуҗалыкларда, СУның ярдәмче хуҗалыгында да инде берьеллык үләннәрдән сенаж салу әйбәт кенә бара. Шулай да шактый ук хуҗалыкларда кичектергесез бу эштә тиешле темп алып китә алмыйлар әле.

Алдагы кышлату чорына терлек азыгы туплау белән бер вакытта киләсе ел турында да бүгеннән кайгыртырга кирәк. Шуңа да хуҗалыклар алдына быел күпьеллык үлән чәчүлекләренең картайганнарын алыштыру, азык культуралары игелә торган мәйданнарны киңәйтү максатыннан җәйдән люцерна чәчеп калдыру бурычы куелды, моның өчен чәчүлек материал белән тәэмин итү хәстәре күрелде. Бу эшнең мөһимлеген аңлаган хуҗалыкларда аны иң отышлы срокларда уздырдылар. «Киекле» хуҗалыгында, мәсәлән, 184 гектарда люцерна чәчелде, әле шуңа 82 гектар костер да өстәлде. «Алга»да бу эшкә җитди карадылар. «Әлмәт», «Заветы Ильича», «Кондырча», «1 нче Май»,»Үрнәк» хуҗалыкларында да люцерна чәчелгән мәйданнар 50 гектардан ким түгел. Шул ук вакытта «Родина», Муса Җәлил исемендәге, «Татарстан», «40 лет Победы», «Таң», «Чирмешән» хуҗалыкларында, МСОның, сөт - май комбинатының ярдәмче хуҗалыкларында, «Дуслык»та чәчәргә орлык була торып та бу эшнең оптималь срокларын кулдан ычкындыралар. Быел һава шартлары бу эш өчен гаять уңайлы килгән җәйге мөмкинлекләр узганны көтеп, аннары «хәзер инде соң» дип акланырга гына җыеналар ахрысы. Ә бит киләсе елда, печән әзерләр чак җиткәч терсәкне тешләрдәй булырлар да, тик ул чакта инде менә чынлап та соң булыр.



Хәмит Мирсәетович Хуҗәхмәтовның механизаторлык тәҗрибәсе тулы бер игенчеләр буыны тәрбияләрлек. Хәер, тәрбияләгәндер дә инде ул! Анардан һөнәр серләренә өйрәнгән яшьләр хәзер үзләре теләсә кемгә киңәш бирерлек булып җитештеләр. Уллары да әтисе янында трактор, комбайн тирәсендә әвәрә килеп үстеләр, шуңа Зөлфәте мәктәптә эшләсә дә җәен кыр корабына утыра, кырлар иңли. Ә остаз үзе дә яраткан һөнәре белән хушлашырга ашыкмый әле. Кышын тракторда эшләсә, җәй игеннәрне җыюда катнаша. Кулына быел яңа ДТ - 75 тракторын тапшыргач, янә күңеле үсеп китте механизаторның. Ә инде район сабанчылар конкурсында катнашу, андагы эшлекле һәм хезмәт кешесенә хөрмәтле обстановканы тою авыл кешесе йөрәгенә янә бәлзәм булып ятты. Хәмит Мирсәетович шул кәефен алда торган мөһим эшләр вакытында да җуймый сакларга, бар күңелен биреп җиргә хезмәт итәргә ниятли.

**Рәсемдә: «Үрнәк» КХАсы механизаторы Х.М.Хуҗәхмәтов.**

## УРТАК НӘТИҖӘ БӨРТЕКЛӘП ҖЫЕЛА

### (Район промышленносте алты айда)

Район промышленность предприятиеләренең беренче яртыеллыктагы эш йомгаклары турында статистика бүлеге игълан иткән мәгълүматлар гомуми нәтиҗәнең бөртекләп җыелуын бик ачык күрсәтә. Һәр предприятие үз урынында кыйммәт дип тәкърарланса да, продукция күләме чагыштырмача азрак булган берничә предприятиенең чагыштырма параметрларга бераз гына тартып бетермәве генә районның гомуми күрсәткечләрендә әллә ни сизелмәскә дә мөмкин. Ә менә районда җитештерелә торган промышленность продукциясенең 85-86 процентын бирә торган НГДУның узган елгы дәрәҗәдән бераз гына чигенүе дә үзен шундук сиздерде - район алты айда чагыштырма бәяләрдә җитештергән продукция узган елгыдан 1,2 процентка азрак чыкты. Ә бит югыйсә абсолют саннарда ул икмәк заводы белән машина төзү заводының икесендә җитештерелгән продукция чамасы гына. Дөрес, промышленность прдукциясенең күләме кимү «Нурлат» агрофирмасы оешып, дуңгызчылык комплексының үз катнаш азык заводы эшли башлау сәбәпле элеваторның продукциясенә сорау азаюдан да килеп чыкты - биредә быел алты айда җитештерелгән катнаш азык узган елгыдан 60, озатылганы 70 процентка кимегән. Ә менә узган елларда продукция җитештерү күләмнәре гел кимүгә барган кайбер предприятиеләрнең бу яртыеллыкта киресенчә яхшырак эшләүләрен билгеләп үтми мөмкин түгел. Аерым алганда, Төрнәс эшкәртү предприятиесе продукция җитештерүне өчъярым тапкырга, сөт - май комбинаты яртылаш диярлек арттыруга ирешкән, икмәк заводы былтыргы дәрәҗәгә якын ук килгән, машина төзү заводы, урман хуҗалыгы, типография дә тотрыклы эшлиләр. Беренчесенең һәм соңгы икесенең июнь аендагы эш күрсәткечләре узган елгыдан аеруча югары булуы игътибарга лаек.

Икенче төп күрсәткеч - кулланучыларга озатылган продукция күләме район буенча узган елның беренче яртысындагыдан 21,1 процентка күбрәк булды һәм бу күрсәткеч предприятиеләрнең дә абсолют күпчелегендә, шул исәптән НГДУда да былтыргыдан югары. Бу җәһәттән иң югары үсешкә (87 процент) ирешкән сөт - май комбинаты һәм машина төзү заводының (79 процент) эш нәтиҗәсендәге алга китеш беренче чиратта авыл хуҗалыгы белән бәйле: беренчеләренә чимал былтыргыдан күпкә артык килсә, икенчеләре авыл хуҗалыгы заказы буенча яңа төр культиваторлар эшләп бирделәр. Икмәк заводы кулланучыларга озаткан продукциянең тулысынча үз кибетләре аша реализациянүен дә билгеләп үтмичә мөмкин түгел.

Предприятиеләрдә җитештерелә торган продукциянең төп төрләренә килгәндә, алты айда 768 мең тоннадан артыграк нефть, эшкә яраклы 3046 кубик метр агач, 860 кубик метр агач материалы чыгарылды, 650 тонна чамасы атланмай, 870 тонналап куе сөт һәм ит, 77 тонна казылык, икмәк заводыннан 700 тоннадан артыграк, райпо пекарняларыннан 475 тонна икмәк сатуга чыгарылды. Соңгыларының да былтыргы дәрәҗәдә диярлек эшләүләре игътибарга лаек. Ә менә райпоның исерткечсез эчемлекләр чыгару күләме тагын кимүгә бара - былтыргының яртысыннан аз гына артыграк. Конкуренциягә сәләтлерәк продукцияләр чыгару турында уйлану зарурлыгын да искәртә торган күрсәткеч бит инде бу.

Күренгәнчә, промышленность предприятиеләренең яртыеллык эш нәтиҗәләре төп параметрлар буенча алганда тынычланырлык. Аларның күпчелегендәге уңай үзгәрешләр алга таба да сакланса, ел ахырына нәтиҗәләрнең тагын да яхшырак буласына нык лап ышанырга була. Өстәвенә, кайбер предприятиеләрдә, бигрәк тә аларның авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү белән бәйле булганнарында эшнең иң киеренкесе дә, нәтиҗә бирә торганы да алда әле.

## ӘЙТКӘН СҮЗ - АТКАН УК

Биккол авылыннан Ф.С.Сибагатуллинны халык депутатларының район Советы депутаты итеп сайлаганда, кандидатка төп наказлары авыл белән Нурлат арасына автобус җибәрү һәм шул ук арадагы юлга асфальт түшәү булды. Халык ихтыяҗын төптән аңлап, үтенечләрне үтәргә вәгъдә итте ул. Бүген бикколлылар вәгъдәләрнең сайлау алдыннан буш сүз генә булып калмавын үз күзләре белән күреп шатландылар: автобус маршруты да ачылды, бүгенге көндә асфальт та түшәлеп килә. «Озакламый төгәлләп тапшырырга исәплибез»,- ди бу эшне башкаручы НУАД начальнигы Һ.Х.Садыйков һәм шунда ук депутатның бу өлкәдә халык наказын үтәүләрен дәвам итү турында искәртә. Соңгысы Бикколны Фома авылы белән тоташтыручы юлга асфальт түшәү булачак. Димәк, киләчәктә бикколлыларга авыл Советына йөрү кыенлыклары да бераз кими, дигән сүз.

## Дөньяданиләр бар?




Чаллыда шәхси телефон элемтәсеннән файдалану күрсәткече һәр йөз гаиләгә 49га якынлашып килә. Хәзер Германиянең «Сименс» фирмасы белән килешү нигезендә элемтәчеләр тагын 10 мең телефонга исәпләнелгән яңа автомат станциясе төзиләр.

***

«Россия - нәрсә эшләргә?» дигән девиз белән Берлинда 150 немец һәм Россия сәясәтчеләре, икътисадчылары, эшмәкәрләре катнашында коллоквиум ачылды. Монда Россия Премьер - министры Виктор Черномырдин белән ГФР канцлеры Гельмут Коль да килде.

***

Франция халыкара радиосы: Европа комиссиясенең инспекция төркеме, эмбарго кертелүгә карамастан, соңгы айларда Англиядән Голландиягә, Мисырга һәм Россиягә 1600 тонна сыер ите чыгарылуын ачыклады. Брюссельдән алынган чыганакларга караганда, Лондон билгеләнгән таләпләргә җавап бирми торган санитария контроле үткәргән. Хәзер инде Европа Советы Англияне суд аша тәртипкә чакырырга ниятли.

***

Башкалабызда шәһәр транспортында йөрү талоннары яңартыла. Бу ксерокопия эше осталарының әлеге өлкәдә «акча эшли» башлаулары белән аңлатыла.

*Алар исемен безнең урамнарыбыз йөртә*

# ТЕЛЬМАН ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ



Тельман Эрнст (1886 - 1944) - немец һәм халыкара эшчеләр хәрәкәтенең танылган эшлеклесе, Германия хезмәт ияләре юлбашчысы, Германия Коммунистлар партиясе үзәк комитеты рәисе.

Гамбургта туган, порт эшчесе булып эшләгән. 1914 - 1918 еллардагы беренче Бөтендөнья сугышында фронтта солдатлар арасында революцион эш алып бара, социал - демократик лидерларның шовинизмын фаш итә. 1920 елда Германия Коммунистлар Партиясенә (КПГ) керә. 1923 елда Тельман кул астында Гамбург пролетариатының героик кораллы восстаниесе уза. Ул кызыл фронтовиклар Союзы белән җитәкчелек итә.

1925 елда КПГ рәисе итеп сайлана. Фашизмга һәм алар әзерләгән басып алу сугышына каршы каты көрәш алып бара. Тельман коммунистлар һәм социал - демократ эшчеләр арасында бердәмлек оештыруга ирешә, реакция һәм фашизмга каршы көрәшә, уң социал лидерларны фаш итә, немец халкын совет халкы белән дуслыкка чакыра.

1924 - 1928 елларда Тельман - Коминтерн Башкарма комитеты членлыгына кандидат. 1928 - 1943 елларда - Башкарма комитет әгъзасы. 1928 - 33 елларда - рейхстаг депутаты. Властька гитлерчылар килгәч, Тельман 1933 елның мартында кулга алына һәм Берлиндагы Моабит төрмәсенә ябыла. 1944 елның августында Бухенвальд концлагерендә фашистлар тарафыннан ерткычларча үтерелә.

Немец эшчеләре, барлык халыкара пролетариат Тельман исемен хөрмәтләп саклыйлар. Аның исеме - немец халкының фашизмга каршы ныклы тынычлык өчен көрәш символы.

**Рубриканы И.САНДЛЕР алып бара.**

*Балалар ялда*

# ЯҢА дуслар, шатлыклар

Балалар һәм яшүсмерләр үзәгендә 5еннән алып 14 нче июльгә кадәр «Яшүсмер» профиль лагеры эшләп килә. Биредә бу юлы 30 бала ял итте. Лагерьда тормыш төрледән - төрле кызыклы, күңелле чараларга бай булды: мавыктыргыч сәяхәтләр, экскурсияләр, викториналар. Беренче көннән үк вожатыйлар районның төрле почмакларыннан җыелган балаларны дуслаштыруны максат итеп куйдылар һәм ул тормышка ашты дияргә дә мөмкин. Дустанә атмосферада балалар табигать кочагында ял иттеләр: үзләре утын әзерләделәр, ашарга пешерделәр, бергәләп җырлар җырладылар. Уеннарның да чиге булмады, ә дуслык учагының кайнарлыгы һәркемнең күңелен җылытты. Кыскасы, балалар атна буе хәрәкәткә бай ял белән мәшгуль булдылар. «Заречный» лагерен да күреп кайттылар, паркта булдылар, елгага су коенырга йөрделәр. «Нептун көне»ндә бик теләп катнаштылар. Дөрес, яңгырлар да булды бу көннәрдә, ләкин ул балаларның кәефен боза алмады. Андый вакытларда алар үз фотосурәтләре белән альбом, пластилиннан төрле фигуралар ясадылар, рәсемнәр конкурслары үткәрделәр. Ә кичләрен видеофильмнар - әкиятләр, үзләренең видеотасмага төшергән үзешчән сәнгать номерларын карадылар.

16 нчы июльдән шәһәр урамнарында балалар җырлары, шатлыклы тавышлары белән үткән автобус күргән булсагыз, белегез, ул балалар һәм яшүсмерләр үзәгенең профиль лагерена җыелучы бишенче смена булыр. Аларны да бездә шундый ук күңелле тормыш көтә.

**С.ФАДЕЕВА,**
**тәрбияче.**

Константин Григорьевич Кудряшов хуҗалыкара төзелеш оешмасының ярдәмче хуҗалыгы әле бер Петровский поселогыннан гына торган чакта да авылдагы егермеләп эш кешесе арасында төп фигуралардан берсе иде. Яшьтән үк тракторга утырган егет эшнең ниндиенә генә тотынса да аны үзе белеп башкаруы белән аерылып тора. Мөстәкыйльлеге аның өйдә дә яшьтән үк йорт башы булуыннан да киләдер дип уйларга кирәк - шәхси хуҗалыкларындагы күпсанлы мәшәкатьләрнең иң авырларын үз башы белән уйлап, үз куллары белән эшләп көн күрергә туры килә аңа. Шуның кебек үк, производствода да кемдер килеп кушканны гына көтеп тора торганнардан түгел Константин Григорьевич, шуңа күрә ярдәмче хуҗалыкның барысы бергә укмашкан төрле участокларында үзенең урынлы фикерен әйтергә дә кыенсынмый. Кирәк була калганда төп вазифасына кермәгән эшләрдән дә баш тартмый.



Хәзер ярдәмче хуҗалык элеккеге колхоз чикләренә кадәр үк җитеп, әле тагын бер - Сосновка поселогын да үз эченә алып зурайгач та Кудряшов үзендәге тырышлык, эшне җиренә җиткереп башкару кебек сыйфатларга тугъры калган хәлдә һаман да иң абруйлы хезмәтчәннәрнең берсе санала. Әле менә сабанчыларның район конкурсына да иң ышанычлы механизатор буларак аны җибәргәннәр иде. Штаттан тыш фотохәбәрчебез Н.КВАШНИНА МСОның «Строитель» ярдәмче хуҗалыгы механизаторы К.Г.Кудряшовны шул көнне рәсемгә төшереп алган.

## Тартуны ничек ташларга?



Дүшәмбедән башларга кирәк. Көненә ярты кап сигарет тартучыларга бу ысул 100 процент гарантия вәгъдә итә. Әгәр инде тәмәке тартучы көненә берәр кап, йә аннан да артык сигарет тарта торган булса, мондый кеше бу начар гадәтне ташлар өчен бөтен ихтыяр көчен эшкә җигәргә тиеш. Һәм монда язылганнарны төгәл үтәү кирәк.

Бер алма аласың. Алма кеше бакчасыннан урланган яки чери башлаган булмасын. Бүләк ителгән алма булса, каршы бүләк бирергә кирәк. Алма эченә сигарет сыешлы куыш ясагыз. Гадәттә, аны гади карандаш белән тишәләр.

Алманы якшәмбе көнне үк караңгы урынга куегыз. Дүшәмбе көнне сигарет кабызып, өч тапкыр суырыгыз да, сигаретны сүндереп, кәгазьгә төрегез һәм алмада ясалган тишеккә тыгып куегыз. (Кәгазь алма эчендә сигарет дымланмасын өчен кирәк). Алманы кабат караңгы урынга куегыз да, эчтән генә әйтегез: «Алма черегән кебек минем яман гадәтем дә китсен». Һәр иртә саен шушы ритуалны кабатлагыз. Пәнҗешәмбе көнне үк сез сигаретка җирәнеп карарсыз, ә шимбә көнне яна кеше булып уянырсыз.

# ШӘХСИ ХУҖАЛЫК - ӨСТӘМӘ ЧЫГАНАК

**Саннарның беренче баганасы - җирле үзидарә Советлары буенча бер сыерга сатып алынган сөт ( килограммнарда), икенчесе - яртыеллык заданиенең үтәлеше (процентларда)**

| | | |
|---|---|---|
| Кычытканлы | 572 | 234 |
| Чулпан | 396 | 155 |
| Яңа Иглай | 393 | 161 |
| Колбай Мораса | 392 | 160 |
| Әмзә | 392 | 160 |
| Урта Камышлы | 370 | 151 |
| Сәләнгеш | 312 | 127 |
| Кормыш | 288 | 118 |
| Егоркино | 251 | 103 |
| Бикүле | 244 | 101 |
| Түбән Норлат | 229 | 94 |
| Иске Әлмәт | 229 | 94 |
| Киекле | 223 | 91 |
| Гәйтән | 190 | 78 |
| Иске Чаллы | 173 | 71 |
| Андреевка | 163 | 66 |
| Якушкино | 161 | 66 |
| Богдашкино | 151 | 62 |
| Тимерлек | 144 | 59 |
| Фома | 140 | 57 |
| Елаур | 115 | 47 |
| Биляр Озеро | 113 | 46 |
| Төрнәс | 110 | 45 |
| Мамык | 70 | 28 |
| Заречный | 26 | 11 |
| Тумба | - | - |
| **Район буенча** | **238** | **97** |

***

Район хакимияте тарафыннан бу эшкә зур игътибар бирелү, хуҗалык җитәкчеләре һәм җирле үзидарә Советлары башлыкларының бу мәсьәләдә кулга - кул тотынышып эшләүләре нәтиҗәсе буларак, быел шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу эше сизелерлек яхшырды: барлыгы 16 мең центнердан артыграк, ягъни узган елның алты аендагыдан ике тапкырдан күбрәк сөт җыелды. Мамык җирле үзидарә Советыннан кала барлык урыннарда да сөтне узган елгыдан күбрәк җыйдылар быел. Кычытканлы, Урта Камышлы, Чулпан җирле үзидарә Советларында узган елгы күрсәткечләрен 329 - 366 килограммга арттыруга ирештеләр. Ә менә Төрнәс, Якушкино, Тимерлек, Биляр Озеро, Елаур җирле үзидарә Советларында узган ел да ташка үлчим генә булган күрсәткечләреннән әллә ни алга китә алганнары юк әле. Югыйсә кайсылары җәмәгать терлекчелегендә дә сөт саву һәм аны дәүләткә сату буенча әллә ни ялтырамаган, димәк, кассаларына акча да бик ишелеп кереп тормаган бу хуҗалыкларда халыкның үз ихтыяҗларыннан арткан сөтен сатып алуын җиренә җиткереп оештырып, бераз акчалата булышлык күрсәтү зыян итмәс иде. Әнә бит, шәхси хуҗалыклардан сөт җыеп алуны даими игътибарда тоткан урыннарда ул эш бүген дә яхшы бара әле: Кормыш, Кычытканлы, Урта Камышлы, Колбай Мораса, Егоркино җирле үзидарә Советларыннан сөт - май комбинатына көн саен тонна - тонна ярым продукция керә.

Хәзер, җәмәгать терлекләре өчен кышкылыкка мал азыгы әзерләү кебек мөһим эш барган чорда шәхси хуҗалыкларны үзләреннән арткан продукцияне дәүләткә сатуда кызыксындыру өчен бу стимулны да нәтиҗәле куллану турында уйларга кирәктер.

*Яңалыклар*

## Шотландиядә Татарстан гимны яңгыраячак

Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле июль ахырында - август башында Бөекбританиянең Абердин шәһәрендә булачак халыкара сәнгать фестивалендә катнашырга җыена. Ул мәртәбәле фестиваль инде 25 нче мәртәбә уза, анда сәнгатьнең төрле вәкилләре - опера җырчыларыннан алып цирк артистларына тикле катнаша. Чыгыш ясаучылар тамашачыларга үзләрен һәм үз сәнгатьләрен генә күрсәтми, тулаем илен, аның традицияләрен дә җиткерә. Шуңа күрә бәйрәмнең дулкынландыргыч тантанасы - анда катнашучы илләрнең дәүләт гимннарын башкару. Быел Абердинда, беренче мәртәбә Татарстан флагы җилфердәү белән бергә, гимныбыз да яңгыраячак. Аны күренекле сәнгать эшлеклебез Лима Кустабаева җитәкләгән Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең оркестры башкарачак.

## Бөек биюче хөрмәтенә

Карнавале музеенда (Париж) дөньяның бөек биючесе Рудольф Нуриевка багышланып ачылган күргәзмә зур популярлык казанды. Ул Нуриевның Вольтер урамындагы фатирын чагылдыра сыман. Анда әлегә аның исемендәге фонд тарафыннан сатылмый калган әйберләр тупланган.

## «Ока»лар арта

Чаллыда КамАЗ ачык акционерлык җәмгыяте составына керүче «Аз литражлы автомобильләр заводы» акционерларының гомуми еллык җыелышы булды.

Узган алты айда биредә 8848 «Ока» машинасы җитештерелгән (узган елның гыйнвар - июнь айларында 2643 шундый машина җитештерелгән булган). Ай саен мең ярым машина чыгарыла. Июльдә 1900 машина эшләп чыгарырга ниятлиләр. Декабрьдә бу санны 2400 данәгә җиткерү күздә тотыла.

# ЭЧКЕ РЕЗЕРВЛАРНЫ ЭШКӘ ҖИГЕП

«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең электр хуҗалыгы, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең энергетика комплексында әһәмиятле буын буларак, нефть чыгару һәм аны озатуда кулланыла торган электр көче җиһазларының уңышлы эшләвен тәэмин итә. Электр җиһазлары һәм электр белән тәэмин итү прокат - ремонт цехы (ПРЦЭиЭ) - идарәнең энергетика службасында үзәк һәм хәлиткеч роль үти.

НГДУның оешкан гына елларындагы юлсызлык шартларында кайбер объектларга барып җиткәнче сәгатьләр уза торган булып, аларны электр энергиясе белән тәэмин итү дә шулай ук озакка тоткарланган чакларда, өстәвенә хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсе дә чамалырак булгач, нефть чыгаручылар бар гаепне электротехник персоналга сылтарга гына тора торганнар иде. Әмма вакытлар узу белән, яңа подстанцияләр сафка бирелеп, фидерлар вагайтылып, ПРЦЭиЭда эшләүчеләрнең һөнәри күнекмәләре тамырдан үзгәреп, юллар да яхшыргач, хәл бөтенләй уңайга китте. Объектларны авария сәбәпле уттан өзү очраклары азайды, электр корылмаларына хезмәт күрсәтүгә зуррак игътибар бирелә башлады, соңгысының сыйфаты да яхшырды.

Электр җиһазларына, электр үткәргечләргә капиталь ремонт үткәрү күләмнәре артуның да уңай йогынтысы зур булды. Хәзер НГДУда ел саен 100 километрга кадәр югары көчәнешле линияләр ремонтлана. Элек бу эшкә баганалар җитмәү проблема булып торса,хәзер андый баганаларны бирүче оешма белән уртак тел табылды.

- Заманында,- дип сөйли НГДУ начальнигы М.М.Хуҗин,- без барлык службалар, шул исәптән энергетиклар алдына да предприятиедәге эчке резервларны мөмкин кадәр киңрәк куллану бурычын куйдык. Шул юнәлештә чаралар, җаваплы кешеләр билгеләнде. Планлаштырылган барлык чараларны төгәл үтәү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирде.

Идарә җитәкчесе әйткәннәрне раслап барлык службалар, аерым алганда энергетиклар службасы эшчәнлегенең уңай нәтиҗәләре турында күп кенә мисаллар китерергә мөмкин.

Менә берсе генә, 1992 елда акрын тизлектә эшләүгә күчерелә торган аз дебетлы скважиналарда акрын әйләнүчән двигательләр куллану мәсьәләсен хәл итәргә алындылар. Ул чакта «Татнефть» берләшмәсенең үзендә дә андый двигательләргә ихтыяҗ бик зур иде. Бүгенге көндә инде ул мәсьәләдә ныклы элемтәләребез бар һәм кискен проблема хәл кылынды. Биш ел эчендә НГДУда сиртмә станокларга 172 акрын тизлекле двигать куелды. Киләчәктә шундый двигательләрне ел саен 15әрне урнаштыру планлаштырыла. Ни әйтсәң дә экономияле, төшемле эш бит.

Энергетиклар нефть чыгаручылар белән кулга - кул тотынышып эшлиләр. Аларның технологлар, производствочылар белән уртак тырышлыгы да средстволарны янга калдыру эшенә юнәлдерелгән. Күтәмәдә күкерт күп нефтьне әзерләү установкасын сафка кертү насос станцияләренә куыла торган сыеклыкның күләмен шактый азайтырга мөмкинлек бирде. Шуңа бәйле рәвештә 3 нче һәм 5 нче өстәмә этем насос станцияләрендә реконструкция ясалып, электр двигательләре азрак көчәнешлеләргә алыштырылды.

139 нчы куст насос станциясендә шурфлар бораулап, кечерәк, әмма җитәрлек кадәр җитештерүчәнлекле горизонталь насослар куелды. 1517 нче куст насос станциясендә заманында һәркайсы 800әр киловаттлы ике насос тора иде. Аларны 90шар киловаттлы батырма насосларга алыштыру да электр энергиясен сизелерлек янга калдырырга мөмкинлек бирде.

Электр цехында үз ремонт - эксплуатация фондлары бар. Сүтеп алынган электр двигательләре шушында калдырыла һәм аларның бер өлеше акрынрак әйләнешле итеп үзгәртеп коруга җибәрелә.

Электр җиһазлары сатып алу өчен финанс проблемасы шулай да кискен булып кала килә. Шул уңайдан нинди дә булса җиһазны ремонтлаганда, югары көчәнешле һәм файдаланылмый торган линияләрне сүткәндә кабат кулланырга мөмкин булган материаллар ремонт эшләренә тотыла. Бу исә ремонтны аз чыгымнар белән дә сыйфатлы итеп башкарырга мөмкинлек бирә.

- Бу елларда,- ди ПРЦЭиЭ начальнигы Ә.Ә.Нәбиуллин,- бездә тәҗрибәле кешеләрдән торган ныклы коллектив тупланды. Аларның яртысыннан артыгы НГДУда 10ар ел һәм аннан да күбрәк эшли. Без коллективтагы һәркем үзен барлык электр җиһазларының хуҗасы итеп тойсын өчен тырышабыз.

Идарәдә 14 нче елын эшләүче цех башлыгы кул астындагы кешеләрнең холык - фигылен дә, тормышларын да яхшы белә. Коллективның үзәген тәшкил иткән кешеләр рәтендә ул электромонтерлар Александр Бражаев, Николай Демидов, диспетчер Сергей Музюков кебекләрне санап китә. Идарәдә уза торган һөнәри осталык конкурсларында аларга тиңнәр юк. Алар электр схемаларын яхшы беләләр, теләсә нинди төзексезлекне көйләп җибәрә алалар. Җыеп кына әйткәндә, чын мәгънәсендә классы белгечләр буларак эшләрен һөнәрмәннәргә хас булганча намус белән башкаралар, производствоның эчке резервларын файдалануда да башкаларга үрнәк булып торалар.

НГДУда түләүле куәтләр структурасын һәм электр энергиясе куллану режимының камилләштерү эше үзенең уңай ахыр нәтиҗәләрен бирә. 1994 елдан башлап идарәдә электр энергиясенә киткән чыгымнар өлеше кимүгә бара. 1993 елда андый чыгымнар барлык чыгымнарның 16,7 процентын алып торган булса, былтыр бу күрсәткеч 7,7 процентка калды.

Дөрес, хәзерге исәп - хисап системасы шартларында алга таба да экономияләүгә ирешүе бик тә кыен. Чыганакларның сулану дәрәҗәсе, технологик куәтләр арту, нефть чыгаруның елдан - ел үсә баруы нәтиҗәсендә бер тонна нефтьне чыгару һәм урнаштыруга тотыла торган электр энергиясе күләме дә үсә бара. Шулай булса да энергетиклар күңелләрен төшермиләр. Чыгымнарны киметү юлларын алар электр энергиясе бирүчеләр белән исәп - хисап ясауның күп тарифлы түләү системасына күчүдә, төгәллек коэффициенты югарырак булган «Альфа» электр хисаплагычлары куллана башлауда күрәләр. Кайбер технологик объектларны, аерым алганда куст насос станцияләрен электр энергиясе кулланучылар азрак булган төнге сәгатьләрдә эшләтүгә күчерү чаралары да эшләнде һәм инде гамәлгә ашырыла башлады.

**В.БУРАЙКИН.**

---

*Ике ел эчендә редакция-типография бинасы белән янәшә заманча зәвык белән төзелгән яңа бина калкып чыкты. Булдыклы кырмыскалардай тыз-быз килүче төзүчеләр аны көн дә төгәлләүгә якынайталар. Кемнәр алар? Шәһәр үзәгендә алар көче белән күтәрелгән бу бина шәһәр тормышында нинди вазифаны үтәячәк? Язмабызда шул һәм башка мәсьәләләргә кагылдык.*

**Шәһәр төзелешләрендә**

# НОРЛАТТА СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ

## Төзелеш «кухнясы»

Норлатта яңа музыка мәктәбе салу мәшәкате 10 еллар элек үк башлана,гамәлдәге музыка мәктәбе иске, таушалган. Сүсәргән күлмәкне ямап кына котылып булмагандай, бу бина да шуңа охшаш хәлгә кала. Шул елларда ТР Министрлар Кабинетының капиталь төзелеш бүлеге заказы буенча проект эшләнә. Ләкин УКСның финанславы өзелеп, төзелеш туктатыла. Һәм менә 1995 елның июленнән финанслау мәсьәләсе яңа көч алып, хуҗалыкара төзелеш оешмасының 547 нче ПМКсы эшкә керешә. Әлбәттә, еллар узган: проект та искерә төшкән, аңа сизелерлек үзгәрешләр кертелә, нигездә бинаны күркәмрәк, рәвешен сәнгатькә якынрак итү чаралары кулланыла. Һәм бүген бинаның төп тышкы эшләре төгәлләнеп килгәндә, Газинур Фәтхуллин, Михаил Огонев җитәкчелегендәге ташчылар бригадаларының әлеге өстәмәләрне уңышлы башкарып чыгулары турында әйтәргә мөмкин. Кечкенә кирпечләрдән зур бина нәкъ шулар тырышлыгы белән күтәрелде. 547 нче ПМК начальнигы Н.Фазлыев, бүгенге көндә биналарны төзүдә сыйфат белән бергә төп игътибарның һәм таләпнең архитектурага, заманча бизәлешкә юнәлтелүе турында искәртә. Чөнки «Югарыда фасад, аркалар ясау бик четрекле эш һәм әлегә безнең өчен өстәмә кыенлыклар тудыра,- ди ул. - Ташчылар өчен шунысы иң кыены булды да. Шуңа карамастан, алар аны бик оста башкарып чыктылар». Хәзер Сергей Селезнев бригадасы түбә ябу белән мәшгуль. Бу җәһәттән тагын бер җиңел булмаган ысул - 12шәр метрлы плитәләрне балкасыз ябу ысулы кулланылуын әйтеп үтәргә кирәк. Интерьерның күркәмлегендә аның роле аз булмаячак. Фәнил Кәлимуллин җитәкчелегендәге балта осталары бригадасы да үз эшләрен белеп башкаралар. Ветераннар Ю.Михеев, И.Лобачев һәм башкалар тирә - якны төзекләндерү белән мәшгульләр. Һәркемнең эше прораб Фәрит Миннегалимов күзәтүе астында бара. 4 сылаучы - буяучылар бригадаларына измәне җиткереп өлгерергә юк: МСОның иң яхшы, сыйфатлы итеп эшләүчеләре саналган Римма Туишева, Тамара Ишкальдина бригадалары әле күптән түгел генә аэровокзал бинасында да үзләрен яхшы яктан күрсәттеләр, биредә дә измәләре тигез итеп стеналарга ята бара. Икенчеләренә килгәндә, алар биредә иң авыр участокта - биеклеге 8 метрлы концерт залында эшлиләр.



Рәсемдә: Т.Ишкальдина бригадасы (ул уртада, сулдан уңга) Н.Маркова, М.Камалиева, Е.Лебакова, Г.Сверлыщкова.

Озакламый җылылык кертүче, санитария челтәрен үткәрүче «Чистай - 2» субподрядчылары һәм төрек бизәүчеләре эшкә керешәчәк.

Кыскасы, бүген МСОның төп көчләре генә түгел, чит көчләр дә бу төзелешкә юнәлтелгән. Алда әле зур эшләр тора, шуңа карамастан объектны 1 нче сентябрьгә тәгәлләп тапшырырга исәпләре бар. Тик шулай да моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бармы соң? Беренчедән, УКСтан финанслау тотрыклы түгел: башкарылган эшкә ярты миллиардка якын сум акча түләнмәгәнен исәпкә алсак, тагын таләп ителәчәк 2 миллиардтан артык акча кайчан бирелер? Әлегә үз средстволарын тоткан предприятиенең финанс хәле гаять мөшкел. Бу хакта бер генә санны мисалга китерү дә дәлил булыр, мөгаен: МСО начальнигы Н.Б.Мөлеков әйтүенчә, бүген предприятиенең эш хакы буенча бурычы 2 миллиардтан артып китте. Бусы икенче тоткарлык. Бина ничек кенә матур һәм заманча булмасын, МСОлыларның кәефләре күтәренке дию дөрескә туры килмәс иде. Юк, бу эшлисе килмәүдән түгел, хезмәт хакы түләнсә икешәр смена эшләүдән дә баш тартмыйлар. Нәкъ соңгысы сәбәпле оешма үзенең квалификацияле кешеләрен югалта да. Чагыштыру өчен, былтыр ПМКда гына бу вакытка 180 кеше исәпләнсә, быел шуларның 40сы юк. Ә МСОда быелның беренче гыйнварена 931 кеше исәпләнсә, бүгенге көндә алар 864кә генә калды. Оешма өчен шунысы кызганыч: дистәләгән елын шул предприятиегә биргән яраткан эшен ташлап китүчеләрнең күпчелеге һәркайда биш куллап алына торган ташчылар.


## «Хуҗалар» планнар төзи

Өлгерәчәк бинаның яңа «хуҗасы» Норлат балалар музыка мәктәбе директоры Т.С.Бадыгин бүлмәләр белән таныштырып йөри.Әле соры измә төсе астында караңгылыкка чумган бүлмәләрнең һәркайсы ның киләчәк вазифасы каралган. Монда баян, нигездә рояль классы... УКСтан 19 рояль алу каралган безгә, ул кадәр үк табып булмас, әлбәттә, алар бик дефицит,пианино да артык түгел безгә.Башкаларыннан зуррак ике бүлмә бар. Берсе-хореография классы, икенчесе-рәсем сәнгате классы булачак. Димәк, без музыка мәктәбе кысаларына гына сыймаячакбыз, дигән сүз. Бу киңрәк, тулырак төшенчәне һәм шундый ук вазифаларны үтәячәк сәнгать мәктәбе булачак.«Балаларны музыка, бию, рәсем сәнгате дөньясына алып керергә биредә зур мөмкинлекләр булыр дип өметләнәбез»,-ди Тәлгать Сәфәргалиевич.Ул шунда ук бүгеннән белгечләр мәсьәләсе дә кайгыртуын искәртә. Концерт залы турында куанып сөйли. Ул 280 урынга исәпләнгән, мәктәп отчет концертларын,гомумән, һәр бәйрәмне иркенләп үзендә үткәрәчәк. Һәм тагын шундый оптимистик планнары аз түгел директорның. Инде эш төзүчеләрдән генә тора.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# Шигъри тәлгәшләр

**Гөлүсә Нугаева**




## Җәйге иртәдә

Хәерле иртә теләп дөньяга
Яңа таң ата, сузыла кояш,
Чирәмдә кала көтүче эзе -
Кипмәгән чык та, салкынча, җиләс.

Авыл уяна азан тавышына,
Шыгырдап куя яңа капкалар.
Әрәмәдәге кәккүк тавышына
- Кушылып китә чалгы кайраулар.

**М.Усманова**

## Сагышлардан мине арала



Җил - давыллап яңгыр ява да,
Тына дөнья, болыт тарала...
Ләйсән яңгыр булып кил дә син
Сагышлардан мине арала.

Туктат та син гомер агышын,
Оныттыр да кайгы - сагышым,
Алып кит тә мине Яшьлеккә
Бәхетле ит минем Язмышым!

Җан җылыңны бир син, кызганма,
Тынычландыр назлап җанымны,
Бәхетле ит мине гомергә -
Нурлы ит син туар таңымны!


Ялгышларын җиңсәк язмышның
Күзләреңнән сине үбәрмен,
Чәчәкләрен мәңге коймый торган
Гөлең булып сиңа түләрмен.

Еллар аша кил дә яныма,
Сагышлардан мине арала.
Төзәлерләр шул чак йөрәктәге
Мәхәббәттән алган яралар.

## Балачак һәм Картлык



И, балачак!
Моңлы бер хатирә!
Бүгенгедәй һаман истә әле,
Яшел үзәндәге түндәкләрдә
Сикергәләп, уйнап үскәнем.
Чумып йөзгән чаклар
«Саз күлендә»
Онытылмый әле бүген дә.
Истә әле...
Матур чәчәкләрдән
Такыялар үреп кигәннәр.
Бәбкә саклый идек бик тырышып
Усал иде ул чак тилгәннәр.
Усал иде ул чак ата казлар,
Усал иде кайбер малайлар.
Чабулардан тешләп тарта иде
Капка астыннан чыгып маэмайлар.
Эх!.. кайтып киләсе иде
Балачакка.



Егылып бер борын канатып,
Йөгереп үтәсе иде урамнардан
Эт өрдереп, каздан талатып.
Олыгайдым...
Казлар куркытырга
Кулларымда хәзер таяк бар.
Була тора борын канатулар -
Абынып кына тора аяклар...
... Үткәннәргә кире кайтып булмый!...

## Төнге ябалак

Бер ябалак төнлә кырда учак күрде,
Ачу белән гайрәтләнеп очып килде
Сүндерәм дип каты итеп кагынды да,
Сүнеп барган учак кинәт кабынды да,
Бичараның пар канаты көеп янды,
Яктылыкны сөймәс җаны утта калды.

### Кызык

# Падишаһлар мутлыгы

Әби патшаның ир - ат белән кети - мети уйнарга яратуы хакында дистәләгән китаплар бар. Мәскәү янындагы Архангельск музеенда (кенәз Юсуповның элеккеге имениесе) бүген дә кызыклы экспонат саклана. Ул әби патшаның картаеп юанайгач, мәхәббәт белән утырып шөгыльләнергә җайлаштырып эшләнгән креслосы.

Гаҗәпмени, патшалар да, президентлар да - адәм балалары ләбаса! Бу җәһәттән алар гына авыз ачып яшәмәс бит инде. Бер акыл иясе әйткәндәй, «кешеләргә хас булган бер генә нәрсә дә аларга чит - ят түгел» ич...

Гитлер үз гомерендә җиде хатын белән җенси мөнәсәбәттә булган. Соңыннан шуларның алтысы үз - үзен үтерергә теләгән, өчесе моны эшләгән дә. Якыннары фюрерны импотент һәм шуңа күрә дә садист булган диләр. Ул сөяркәләрен типкәләгән, камчы белән суктырган. Ә Гели Рабул дигәнен шәрә килеш төрле кыяфәтләрдә рәсемгә төшерергә яраткан.

Италия диктаторы Муссолини үзенең шоферы белән Римның барлык почмакларын йөреп чыга. Еш кына хатын - кызны эш бүлмәсенә дә алып керә. Шофер сүзләренә караганда, ул хатын - кыз янында чалбар һәм ботинкаларын да салырга «онытa» торган була.

Тир исе аңкып торган, алама киенгән пычрак хатыннардан да чирканмаган, аларга кычкырынган, сүгенгән, әмма барыбер үзенекен эшләгән. Җикеренгәнен башкалар ишетмәсен өчен ишек янына саңгырау сакчыларын куя торган булган.

Согуд Гарәбстаны короле Ибан Сауд - 300 хатынның ире. Дөрес, аларның 4се генә законлы. Ләкин ул каядыр барганда аларны аерып, икенчеләрен алып китә. Һәр хатынның үз өе булып, король аларга чиратлап йөргән һәм бурычын намус белән үтәгән.

Болардан тыш аның сарай тулы сөяркәсе һәм тол хатын - кызлары да булган.

Иран шаһы Риза Пәһләви дә мәхәббәт өлкәсендә төшеп калганнардан булмаган. Бу эш белән ул хәтта вертолетта очканда да шөгыльләнгән. Франциядә уйнаштан туган баласы калган. Сент - Морицта ял иткәндә, вилладагы хатыныннан качып китеп, отельгә барып урнашып, шундагы фәхишәләр белән мәхәббәт диңгезендә тирбәлгән.

Венеция кинофестивәленә килгәч, дип хәтерли Италия премьер - министры Андреотти, шаһ шәһәр магистрыннан төнгелеккә сөяркә таптырган.

Пәһләвине Ираннан кугач, ул Панамада туктый. Берчакны аны АКШның илчесе эзли башлый һәм Панама Президентына шалтырата. «Ул хатыннар янында», дип җавап бирә Президент.

1986 елда Ливия башлыгы Муаммар Каддафи үзенең хатыны һәм балалары белән таныштыру өчен биш хатын - кыз журналистны өенә чакыра. Кызып алгач, ул кунакларның аеруча чибәр өчесенә кул суза башлый. Америка журналисты моңа түзеп тора алмый һәм отеленә кайтып китә.

Икенче берсенә хуҗа: «Синең карашларың матур. Мине бер төнгә, һич югында, бер сәгатькә булса да дөнья мәшәкатьләрен онытырга мәҗбүр ит»,- ди. Теге һәм Австриядән килгән Рената Поссаминг монархка каршы килә алмыйлар... Каддафи аларны кыйммәтле бүләкләр белән күмә...

Менә шундый үрнәк ата һәм тугрылыклы ир булганнар падишаһлар.


## Белдерүләр

### Сатабыз

**ВАЗ - 2106га яңа двигатель**. Тел.: 5 - 23 - 25.

***

**1994 елгы УАЗ - 31514 (люкс) автомашинасы**. Тел.: 5 - 23 - 96, 17 сәг.тән соң.

***

**1993 елгы «ИЖ - Планета - 5» мотоциклы, 4000 км. юл үткән.** Тел.: 2 - 15 - 93.

***

**ГАЗ - 51, 52 машинасына эчлекләр. Тамыр эчлек - 1,50 - 0,05, пешкәкле - 0,75 - 0,25 - 0,5 - 0,05.** Рус Мәнҗесе авылында Черновка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ике һәм өч камералы «Норд» суыткычлары (Донецк шәһәре). Югары ышанычлылык, евродизайн, түбән бәяләр, гарантия, район эчендә бушлай китереп бирү**. Тел.: 2 - 11 - 24 яки 5 - 19 - 95. Лицензия - А - 96 118575.

***

**Йорт**. Адрес: Западная ур., 9.

***

**Югары Ослан район үзәгендә йорт яки дача төзү өчен 15 сутый участок (Казаннан теплоходта 30 минут). Иске йорты, бакчасы, табигый газы, суы бар**. Тел.: 2 - 11 - 24.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир. Ремонт үткәрелгән, идән асты, сарае, телефоны бар**. Адрес: Гагарин ур., 4 - 1 яки 4 - 4.

***

**«Epson ex 300» принтеры, кыйммәт түгел. «Украина» кинопроекторына көчәйткеч сатып алам**. Тел.: 5 - 26 - 19.

***

**1986 елгы ВАЗ - 2121 «Нива» машинасы.**
Тел.: 2 - 17 - 79, 5 - 24 - 56 (18 сәг.тән соң).

***

**1990 елгы, әйбәт хәлдәге «Москвич 2124»**. Чишм поселогында Ринатка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Йорт төзү өчен төзелеш материаллары белән участок**, Арадашчы адресы: Лермонтов ур., 14, Сашаны сорарга.

***

**1991 елда чыккан ВАЗ - 2106.** Адрес: Кычытканлы авылы, Ибраһимов И.И.

***

**Ашыгыч рәвештә ике бүлмәле фатир**. Тел.: 5 - 14 - 07.

### Төрлесеннән


**Казандагы бер бүлмәле фатир - өстәмә түләп Норлаттагы шундыйга ук алыштырыла.** Норлат шәһәре, Гагарин ур., 28 - 27 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**1 нче мәктәпне бетерү турында Никифорова Елена Николаевна исеменә бирелгән АС 0030924 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.**

**Көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча «Надежда» дәүләт предприятиесе тотылган машиналар сата: ГАЗ - 53, УАЗ - 3303. Бәясе - килешү нигезендә. Эшчеләр җыя:**
1. **МТЗ тракторчылары;**
2. **Столяр;**
3. **Тегү җиһазлары буенча механик - электрик;**
4. **Аяк киемнәре ремонтлау буенча мастер.**

***17 июль көнне 18.00 сәг.тә Илют-кино мәктәбен 1980 елда тәмамлаучыларның очрашуы була.***



**«Норлатнефть НГДУсының «Зорька» сөт - май комбинаты килограммын 21 мең сумнан ак май, литрын 1870 сумнан 3,2 процентлы, литрын 250 сумнан аертылган сөт сата.**



***Вишневая Поляна мәктәбен 1982 елда тәмамлаучыларның очрашуы 19 июльдә 17 сәг.тә булачак.***



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 дана Заказ N 7184